Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Тюгеевского
сельского поселения Заинского
муниципального района

ул. Центральная, д. 8, с. Тюгеевка,
Заинский район, 423507

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Төги авыл җирлегенең
башкарма комитеты

Үзәк урамы, 8 нче йорт, Төги
авылы, Зәй районы, 423507

Телефон, факс 60-5-48. Электронный адрес: Turg.Zai@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**19.12.2018 ел** **№ 18**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Төги авыл җирлеге Уставы, «Гражданнарның үзара салымы турында» 2014 елның 21 февралендәге 105 номерлы Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге Советы карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге башкарма комитеты

**карар итте:**

1. Төги авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет житәкчесе** **Т.В.Попова**

Зәй муниципаль районы
Төги авыл җирлеге
башкарма комитетының
2018 елның 12 декабрендәге
18 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Төги авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчалары киләсе календар елның 15 февраленә кадәр Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан кала, җирле референдумда (җыенда) катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан түләнә.

3. Түләми тору өчен нигезле сәбәпләр булып түбәндәгеләр торырга мөмкин:

а) вакытлыча хезмәткә яраксызлык (6 айдан артык),

б) оешманы бетерү, оешма хезмәткәрләренең санын яки штатын кыскарту сәбәпле эштән азат ителү,

гражданнарга гариза нигезендә түләүне кичектерү ике айдан да артык булмаган вакытка бирелергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә (белдерү) бланкы турында гражданнарга хәбәр җирлекнең рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру, кул куйдырып, кулга бирү юлы белән җиткерелә, почта элемтәсе аша җибәрелә.

Хәбәрнамәдә (белдерүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салым акчалары Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша почтадан акча күчерү юлы белән (исәп-хисап оешмалары), Төги авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының https://uslugi.tatarstan.ru сылтамасы аша башкарыла.

7. Түләү фактын раслый торган документлар булып приход касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар тора.

8. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Зәй муниципаль районы
Төги авыл җирлеге
башкарма комитетының
2018 елның 12 декабрендәге
18 номерлы карарына
2 нче кушымта

Төги авыл җирлеге бюджетына бер тапкыр түләнә торган салымны
түләү турында _____ номерлы
ХӘБӘРНАМӘ (БЕЛДЕРҮ)

Түләүченең
Ф.И.А.________________________________________________
Адресы: _______________________________________________
Сезгә _________________________________нигезендә __________
вакытында кадәр _______________________чараларны тормышка ашыру
өчен бер тапкыр ________________ сум күләмендә түбәндәге реквизитлар
буенча салым түләргә кирәк.
Банк БИК ______________________________________
Сч. № ___________________________________
Алучы Сч. № ___________________________________
ИНН ____________________________________________
КПП ____________________________________________
КБК ________________ ОКАТО __________________
Түләүнең билгеләнеше______________________________________

Җитәкче __________________ ____________________________________
(имза) (имза тулысынча)
М.У.

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Белдерү) No ____

_______________________________________________________________
(муниципаль берәмлек исеме)
бюджетына үзара салым буенча _______________суммада бер тапкыр түләү
турында
Түләүченең Ф.И.А. ____________________________________
Адресы: ______________________________________________________
Алынган «__» ________________ 20__ ел

____________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Өзеп бирелә торган квитанция тутырыла һәм түләүчегә хәбәр шәхсән тапшырылганда төпсә_____________авыл җирлеге башкарма комитетында кала.*